Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР №16**

Зур Мәшләк авылы 2024 елның 1 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Кадрия Әсхәт кызы Шәмсевәлиеваның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсендәге 6 өлешенең 2 пункты, 7 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 маддәсендәге 8, 9 өлешләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 46 маддәсендәге 1 өлешенең 2 пункты, 2 өлеше, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2024 елның 1 октябрендәге 15 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаруны Шәмсевәлиев Миннеәхмәт Минневәли улына йөкләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы рәисе вазыйфаларын башкаруны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Вафина Валентина Ивановнага йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшлек авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшлек авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручы турында» 2024 елның 1 июлендәге 12 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

5. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 13А йорты, Югары Мәшләк авылы, Нариманов урамы, 24а йорты, Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы урынбасары В.И. Вафина